ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
ДӘҮЛӘТ СОВЕТЫ
**КАРАРЫ**

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советының дүртенче утырышы көн тәртибе турында

Татарстан Республикасы Дәүләт Советы КАРАР БИРӘ:

Җиденче чакырылыш Татарстан Республикасы Дәүләт Советы дүртенче утырышының түбәндәге көн тәртибен расларга:

1. Татарстан Республикасы Иҗтимагый палатасы әгъзасын раслау турында.
2. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы бюджеты турында» 5-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
3. «2025 елга, 2026 һәм 2027 еллар план чорына Татарстан Республикасы Территориаль мәҗбүри медицина иминияте фонды бюджеты турында» 6-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты хакында (I укылыш).
4. «Татарстан Республикасы территориясендә автомобиль юллары һәм юл эшчәнлеге турында» Татарстан Республикасы Законының 11 һәм 13 статьяларына һәм «Татарстан Республикасында юл хәрәкәтен оештыру өлкәсендә аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законына үзгәрешләр кертү хакында» 596-6 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
5. «Административ хокук бозулар турында Татарстан Республикасы кодексының 3.2 һәм 3.16 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында» 7-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).
6. «Янгын куркынычсызлыгы турында» Татарстан Республикасы Законының 4 статьясына һәм «Халыкны һәм территорияләрне гадәттән тыш

хәлләрдән яклау турында» Татарстан Республикасы Законының 9 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 11-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

7. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексына үзгәрешләр кертү хакында» федераль закон проектын Россия Федерациясе Федераль Собраниесе Дәүләт Думасына кертү буенча Татарстан Республикасы Дәүләт Советының закон чыгару инициативасы турында.

8. «Татарстан Республикасында гражданнарның сәламәтлеген саклау өлкәсендәге аерым мәсьәләләрне җайга салу турында» Татарстан Республикасы Законының 25 статьясына үзгәреш кертү хакында» 10-7 номерлы Татарстан Республикасы законы проекты турында (I укылыш).

9. «Россия Федерациясендә мәгариф турында» Федераль законның 71 статьясына үзгәреш кертү хакында» 686334-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе җинаять-үтәтү системасы хезмәткәрләренең балаларына югары белем бирү мәгариф оешмаларына керүгә өстенлекле хокук бирү өлешендә).

10. «Мәгълүмат, мәгълүмат технологияләре һәм мәгълүматны яклау турында» Федераль законның $10^6$ һәм $15^1$ статьяларына һәм Россия Федерациясенең аерым закон актларына үзгәрешләр кертү хакында» 724769-8 номерлы федераль закон проекты турында (бала табудан баш тартуны пропагандалый торган мәгълүматны тыю өлешендә).

11. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 24.5 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 713197-8 номерлы федераль закон проекты турында (Россия Федерациясе субъектының дәүләт хакимияте органы яисә җирле үзидарә органы вазыйфаи заты тарафыннан әлеге органнарда булган яисә аларга тапшырылган вәкаләтләрне, мондый вәкаләтләрне гамәлгә ашыру өчен аларга бюджет ассигнованиеләре яисә субвенцияләр бирелмәгән (җитәрлек бирелмәгән) очракта, үтәмәү яисә тиешенчә үтәмәү хакында административ хокук бозу турында эш алып баруны туктату хакында).

12. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 6.21 статьясына үзгәрешләр кертү хакында» 724905-8 номерлы федераль закон проекты турында (бала табудан баш тартуны пропагандалаган өчен җаваплылык кертү өлешендә).

13. «Административ хокук бозулар турында Россия Федерациясе кодексының 3.5 һәм 19.23 статьяларына үзгәрешләр кертү хакында»

729113-8 номерлы федераль закон проекты турында (законсыз миграцияне оештыру максатларында ялган документлар ясаган өчен җаваплылыкны көчәйтү өлешендә).

14. Хөкүмәт сәгате: «Татарстан Республикасы Юстиция министрлыгының җирле үзидарә органнарына хокукый ярдәм күрсәтү максатларында алар белән хезмәттәшлеген оештыру турында».

15. Төрлесеннән.

Татарстан Республикасы
Дәүләт Советы Рәисе Ф.Х. Мөхәммәтшин

Казан шәһәре,
2024 елның 9 октябре
№ 75-VII ДС